# КАРАР

## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2024 ел, 14 ноябрь № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 22 октябрендәге 188 номерлы карарына нигезләнеп,

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерүне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча 2024 елның 14 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 208 (Ике йөз сигез) граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 112 кеше, бу 53,8 % тәшкил итә;

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча, җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 112 (Йөз унике) кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенның 0 (ноль) катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алан-Бәксәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенә кергән Алан-Бәксәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне:
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- урамнарны яктырту җайланмаларын төзекләндереп тору;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү;
- торак пункт территориясен төзекләндерүне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә Сез ризамы?”

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

соравы буенча уңай карар кабул ителде дип танырга.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы: З.Р.Гарифуллина